**РУХИ МАЯК**

Татарстанда иң борынгы агач мәчет төзекләндерүдән соң ачылды

> 2

**«ТНВ»ДА ПРЕМЬЕРА:**

«Бер-бер хәл» сериалы чынбарлыкны тасвирлый

> 3

**ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР**

«Ватаным Татарстан» газетасыннан бүләк алу шартлары

> 4

**НОМЕРДА – ДОКУМЕНТ**

2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына республика бюджеты турында

> 5-58


# ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 159 (28741) | Шимбә | 30 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131


# КЫШ КӨТМӘГӘНДӘ КИЛӘ

## ТАТАРСТАННЫҢ БАШ ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКТОРЫ КӨПЧӘКЛӘРНЕ ВАКЫТЫНДА АЛМАШТЫРЫРГА КИҢӘШ ИТӘ

Хәерле юл!

**Быелның тугыз аенда Татарстан юлларында 11 баланың гомере өзелгән. Чагыштыру өчен: былтыр ел буена (!) республика юлларында 9 бала үлгән. Коточкыч саннар бу! Юлда гомерләре кыелган сабыйлар барысы да пассажир булган. Бу хакта кичә «Татар-информ» агентлыгында узган матбугат очрашуында Татарстанның ЮХИДИ идарәсе башлыгы Ленар Габдрахманов хәбәр итте.**

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балалар катнашындагы юл һәлакәтләренең күбесе алар утырган машина йөртүчеләр гаебе белән килеп чыккан. Хәтерләсәгез, әле июль азагында гына Әлмәттә килеп чыккан юл һәлакәтендә 2 яшьлек баланың гомере өзелде. Тикшерү барышында әтисенең исерек булуы, сабыйның исә махсус утыргычка утырмавы ачыкланган. «Машинасында балалар утыргычы була торып та, аны кулланмаучылар бар. Аның сабый гомерен саклап калучы ышанычлы чара икәнлеге күпсанлы тикшеренүләр ярдәмендә дәлилләнгән инде. Шуңа күрә ата-ана баланың куркынычсызлыгына җаваплырак карасын иде. Бу кагыйдәне бозган өчен 3 мең сум күләмендә штраф салына. Утыргычның да бәясе шул тирә. Акчаны янга калдыра торган очрак түгел бу», – диде Ленар Габдрахманов. Татарстанның баш дәүләт инспекторы көзге каникул чорында юлларда аеруча игътибарлы булырга чакырды. Балаларның үзләренә дә юл кагыйдәләрен тагын бер кат искә төшерү артык түгел, билгеле. Юл хәрәкәте бусаганы атлап чыгуга ук башлана.

Татарстанның ЮХИДИ идарәсеннән алынган мәгълүматларга караганда, быел республика юлларында 2890 юл һәлакәте теркәлгән. Бу узган елгыдан 13 процентка азрак. Быел республика юлларында килеп чыккан юл һәлакәтләрендә имгәнүчеләр, һәлак булучылар саны узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда азрак булган. 217 машина йөртүче һәлакәт урыныннан качкан. «Юл һәлакәтләре саны кимесә дә, тынычланырга хакыбыз юк. Ни кызганыч, Татарстанда көн саен уртача 8–10 юл һәлакәте килеп чыга», – ди ЮХИДИ идарәсе башлыгы.

Ленар Габдрахманов кышның көтмәгәндә килә торган гадәте барлыгын да истән чыгармаска киңәш итте. «Тимер ат» ияләренә, эшне ахыргача сузмыйча, кышкы көпчәкләргә күчәргә тәкъдим итте ул. Хәтерләсәгез, узган ел ноябрендә һава торышы кинәт кенә бозылып алды. 22–24 ноябрь көннәренә туры килде ул. Шушы өч көн эчендә республика юлларында 580 юл һәлакәте теркәлгән. Аларда 9 кешенең гомере өзелгән, 40 кеше имгәнгән. «Шуңа күрә һәлакәткә эләкмәс өчен вакытында кышкы көпчәкләргә күчәргә һәм тизлек турында онытмаска кирәк», – дип искәртте республиканың баш инспекторы. Тизлек дигәннән, сентябрьдән башлап илнең күп кенә төбәкләрендә, шул исәптән Татарстанда да, уртача тизлекне арттырган өчен штраф салынмый башлады. «Ләкин якын арада бу мәсьәлә кабат каралачак», – дип белдерде Ленар Габдрахманов.

ЮХИДИ идарәсе юл кагыйдәләрен бозучыларны ачыкларга ярдәм иткән кешеләрне бүләкли башларга да җыена. Моның өчен кагыйдә бозу очрагын теркәгән видеоны социаль челтәрләргә урнаштырырга гына кирәк. Ел башыннан бирле әлеге ысул ярдәмендә 161 машина йөртүчегә 350 мең сумнан артык штраф язганнар инде. «Татарстанның ЮХИДИ идарәсе юл кагыйдәләрен бозу очракларын ачыклау өчен социаль челтәрләргә даими рәвештә мониторинг үткәрә. Андагы мәгълүмат нигезендә кагыйдә бозган машина йөртүче тикшерелә, җавапка тартыла», – диде Ленар Габдрахманов.

Инспекторлар социаль челтәрләргә эленгән андый видеоларны ике төркемгә бүлеп карый икән. Беренчеләрен юл кагыйдәсен бозган машина йөртүчеләр үзләре үк урнаштыра. Алар моны, нигездә, игътибарны җәлеп итү, заманча итеп әйтсәк, хайп өчен эшли. Видеоларның икенче бер өлешен исә юл кагыйдәләрен бозган машина йөртүчеләрне читтән төшереп торган кешеләр урнаштыра. «Андыйлары көннән-көн арта бара. Мондый рухтагы видеолар гына урнаштырылган махсус пабликлар да пәйда була башлады. Шуларның берсен тикшерү барышында гына да соңгы ике атна эчендә 16 машина йөртүче җаваплылыкка тартылды», – ди Ленар Габдрахманов. Юл кагыйдәләрен бозган машина йөртүчеләрне ачыкларга ярдәм иткән иң актив кешеләрне бүләкләргә дә вәгъдә итте ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

| ЮЛДАГЫ ВАЗГЫЯТЬ – САННАРДА | 2021 елның 9 ае | 2020 елның 9 ае |
|---|---|---|
| Юл һәлакәтләре саны | 2586 | 2956 |
| Имгәнүчеләр | 3 566 | 4055 |
| Үлем-китем очраклары | 247 | 263 |
| Балалар катнашындагы аварияләр | 344 | 354 |

# Коронавирус чигенергә теләми

Республикада коронавируска каршы прививка ясатучылар 1,5 миллион кешедән артып китте. Хәзер андыйлар – 1526214 кеше. 1,5 миллионынчы булып Казанда яшәүче 26 яшьлек Юлия Сабирова тарихка кереп калды. «Иң элек үз сәламәтлегемне кайгырту ниятеннән вакцинация узарга килдем. Прививка ясатмаучыларның барысына әйтәсе килгән сүзем шул: ясатыгыз! Бик кирәк ул!» – дигән кыз.

Узган тәүлектә Татарстанда COVID-19 инфекциясен йоктыруның яңа 183 очрагы теркәлгән. 2 кеше чирне читтән ияртеп кайткан, 181е сырхаулар белән аралашу сәбәпле йоктырган. 59 кеше хастаханәгә салынган, 124е өендә дәвалана. Иң күп чир йоктыручылар, элеккечә үк, Казанда (83), Чаллыда (27). 29 октябрьгә алынган мәгълүматларга караганда, пандемия башланганнан бирле республикада барлыгы 30416 ковид йоктыру очрагы теркәлгән. Шушы чорда 25103 кеше савыккан, шул исәптән соңгы тәүлектә – 118 кеше.

# *Пенсиягә өстәмә түлиләр*

Россия Хөкүмәте 2022–2024 елларда кереме төбәктәге яшәү минимумыннан кимрәк булган эшләмәүче пенсионерларга социаль өстәмә түләү өчен 134 миллиард сумнан артыграк акча бүлеп бирәчәк. Бу хакта ТАСС хәбәр итә. Агентлык карамагына Россия субъектларына федераль бюджеттан тиешле субсидияләр бирү кагыйдәләре урын алган документ килеп кергән. Документтагы мәгълүматлардан күренгәнчә, 2022 елда пенсиягә өстәмә рәвешендә 41,8 миллиард сум, 2023 елда – 44,57 миллиард, 2024 елда 47,9 миллиард сум чамасы акча тотылачак. Узган елда 6,2 миллион пенсионер шундый өстәмә акча алган. Федераль өстәмәнең уртача күләме аена – 1967 сум, төбәкнеке 4924 сум тәшкил иткән. Пенсиягә социаль өстәмә акчасы төбәктә пенсионерның яшәү минимумы күләменә җиткереп билгеләнә.

Сүз уңаеннан, 2022 елдан Россиядә пенсиягә социаль өстәмәне гариза тапшырмыйча гына алырга мөмкин булачак.

# Ялган акча кермәсен

Быел өченче кварталда Татарстан банкларында барлыгы 116 кәгазь акчаның ялган булуы ачыкланган. Бу – алдагы өч айдан 55 процентка кимрәк. Россия банкының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте шулай дип хәбәр итә. Күпчелек очракта эре акча ялган булып чыккан. 5 мең сумлык – 99, 1000 сумлык – 12 һәм 2 мең сумлык 2 ялган кәгазь акча ачыкланган.

Моннан тыш, өч ай эчендә 100 долларлык ике акчаның ялган булуы ачыкланган.

Белгечләр искә төшереп үткәнчә, кәгазь акчада кимендә өч саклагыч билгене тикшерергә кирәк. Су билгесе, саклагыч җеп, төсен үзгәртүче буяу кебек билгеләрне махсус җиһазларсыз да күрергә мөмкин.

# *Ярминкә дәвам итә*

Бүген Казанда гадәттәге авыл хуҗалыгы ярминкәләре гөрләячәк. Сәүдә иртәнге 6дан башланып көндезге 12гә кадәр дәвам итәчәк, дип хәбәр итә шәһәр мэриясе. Ярминкә Казанның барлык 7 районында үткәреләчәк. Шулай ук «Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләрнең үтенече буенча, Осиново бистәсендәге «Радужный» сәүдә үзәге парковкасында да шимбә ярминкәсе узачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Эшмәкәрләргә ярдәм

# Җиде юл чатында калмаслар

**QR-кодлы тормыш, эшләми торган атна бизнес вәкилләренең кесәсенә шактый сугачагы фаразланган иде инде. Эшмәкәрләр югалтуларын санаган арада, хөкүмәт аларны ярдәмсез калдырмабыз дип ышандыра. Икътисад министрының беренче урынбасары Рөстәм Сибгатуллин шулар турында сөйләде.**

QR-кодлар кертелгәннән соң бизнес-вәкилләре белән уртак тел таптык, аларның ихтыяҗ һәм теләкләре дә исәпкә алынды, дип ышандырды министр урынбасары. «Күпчелек мөрәҗәгатьләр эшчәнлеге сәүдә белән бәйле эшмәкәрләрдән килде. Яртысыннан артыгы – керем, тагын бер өлеше сәүдә үзәкләренә йөрүчеләрнең кимүеннән зарланды. Шул ук вакытта эшмәкәрләрнең 63 проценты хезмәткәрләргә мәҗбүри вакцина ясату белән бәйле кыенлыклар юк дип белдерде», – ди Рөстәм Сибгатуллин.

Бизнеска нәрсә кирәк? Пандемиянең беренче дулкыннарыннан соң әле яңа сулыш алган бизнес вәкилләренә, әлбәттә, бу шартларда элеккеге ярдәм чаралары да ярап куяр иде. Россия Хөкүмәте узган атнада ук ташламалы шартларда кредит алу, микрозаймнар турында аңлаткан иде. «ФОТ 3.0» дигән программаның кабат эшләтеп җибәрүләре турында да әйттеләр. Аның ярдәмендә займнарны кире кайтару вакыты тагын 6 айга чигереләчәк.

Программаның яңа этабында әлеге ярдәм чарасыннан матурлык салоннары, компьютер техникасын төзекләндерү, химчистка, стоматология, өстәмә белем бирү, балалар карау белән шөгыльләнүчеләр дә файдалана ала. Моның шарты: хезмәткәрләрнең 90 проценты эш урынында калырга тиеш. Шәхси эшмәкәрләр, компанияләр бер хезмәткәргә бер МРОТ күләмендә грант алырга хокуклы. Гаризаны 1 ноябрьдән башлап салым хезмәте аша кабул итәләр. Түләү 15 ноябрьдән алып 31 декабрь аралыгында башкарылачак.

Бизнес вәкилләрен элек алган кредитларны реструктуризацияләү мәсьәләсе дә борчый. Мәгълүм булганча, Россия Үзәк банкы банк һәм микрофинанс оешмаларга элегрәк реструктуризацияләү кичергән кредитларны да реструктуризацияләргә тәкъдим иткән иде. Килешүне бозган затларга штраф, пенялар өстәмәскә дә кушылды. Моңа бәйле сорауларны республиканың Икътисад министрлыгының «кайнар элемтә» номерына **(843 (524-90-90)** шалтыратып җиткерергә мөмкин.

Федераль хакимият ярдәменә өметләнә алмаган эшмәкәрләргә Татарстан үзе булышачак.

– Чикләү чараларын кертүдән зыян күргән бизнес категорияләренә ярдәм күрсәтү турында карар кабул иттек. Бу, нигездә, сәүдә белән бәйле тармаклар. Әйткәнемчә, иң күп мөрәҗәгатьләр алардан килә, – диде Рөстәм Сибгатуллин.

Аларга Татарстан хакимияте бер процентлы микрозайм тәкъдим итә. Узган ел бу ярдәм чарасы үзенең кирәклеген раслаган инде. Татарстан эшмәкәрләре аннан файдалану өчен гаризаны 1 ноябрьдән башлап 31 декабрьгә кадәр тапшыра ала. «Теләсә нинди нигезле максатлар өчен бирелә торган ташлама бу. 300 мең сумнан 1 млн сумга чаклы акча алырга мөмкин», – дип искәртте министр урынбасары.

Татармын! Горурмын!

**Гөлзада САФИУЛЛИНА, Татарстанның халык артисты:**

Һәр халыкның үз мәдәни коды бар. Ул әле бар, һәм шушы код безне саклый. Балалар русча җырлар, рэп тыңлый. Ә шушы бала үз мохитебезгә эләксә, ул сискәнеп китә, үзен кая куярга белми, галәмгә очкан шикелле була. Мәдәни код үз эшен эшли. Күпме генә бүген безне укмаштырып-чукмаштырып руска әйләндерергә теләсәләр дә, барыбер мәдәни код бетмәячәк.

**(«Интертат» электрон газетасыннан)**

# КОРОНАВИРУСКА БӘЙЛЕ ХОКУК БОЗУЛАР

**Татарстан буенча эчке эшләр министры урынбасары Алексей Соколов әйтүенчә, республикада QR-код системасы үтәлеше даими тикшерелә. Санлы күрсәткечләрдә – 11 октябрьдән башланган тикшерүләрнең нәтиҗәләре.**

| QR-код системасына бәйле хокук бозулар | COVID-чикләүләрне үтәмәгән өчен | Битлек кию режимын санга сукмаучылар |
|---|---|---|
| 41 очрак – ялган QR-код | 1 меңнән артык беркетмә – физик затларга | 600дән артык кеше (бер тәүлеккә) |
| 312 административ эш – оешма һәм вазыйфаи затларга карата | 124тән артык беркетмә – юридик затларга | |

## ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

# «Өс»ләр теләми, «ас»лар булдыра алмый

Дөньябыз яшәгән саен катлаулана. Ни өчен катлаулана? Беренчедән, техник, технологик прогресс зур адымнар белән алга атлый. Атламас та иде, аңа коточкыч олы күләмдәге акча юнәлтелә. Капитализм шартларында башкача була да алмый торгандыр ул. Керем чыганаклары эзләп, аларны даими табып тормасаң, «фәкыйрь»ләр рәтенә төшүең дә бар. Фән, техника – иң табышлы инвестицияләрнең берсе бүген. Төрле илләрдәге галим-голәмә, инженерлар, микроэлектроникада атомара ераклык белән эш итеп, моннан ике-өч дистә ел элек уйда да булмаган төрледән-төрле гаджетлар уйлап таба, портатив атом реакторлары әвәли, физик хезмәттән котылу өчен роботлардан гына торган заводлар булдыра, йөртүчесез автомобильләр җыя. Технологик революция – беренче карашка барысы да кеше, аның мәнфәгатьләре өчен кебек. Тик техник алгарыш кешелек алдына яңадан-яңа проблемалар китереп куя, искеләрен кискенләштерә. Экологик хәл куера, яңадан-яңа корал системалары тыныч, имин яшәүне кыенлаштыра, гибрид сугышлар ярала, гавам глобализм дигән шикле шаукым – унификациягә, күңел кайтаргыч бертөрлелеккә биреша.

Икенчедән, саналганнар өстенә әле тагын безнең күзгә кереп, колакка ирешеп торган мәгълүмат күләме дә көннән-көн арта. Газета укыйсы, радио кабызасы да юк. Бар яңалык синең кулыңнан төшмәгән айфонда. Информация артуда артык криминал бәлки булмас та иде, тик менә мәгълүматның күпчелеге негатив форматта. Кеше заты үзе шундыйга хирыс, күбрәк шуның белән туена. Радио, телевидение, интернетта контент тудыручылар моны яхшы белә. Кайдадыр булган җир тетрәү, бәла-каза, фетнә-чуалышлар, вак сугышлар, корбаннар, илләр арасындагы кискен мөнәсәбәтләр, икътисади һәм сәяси кризислар, тотрыксызлык бәндә күңеленә сары май булып ятмаган тәкъдирдә дә игътибарны күпкә ныграк җәлеп итә. Бүгенге глобаль мәгълүмат кырын негатив эзләп, табып, аны таратып йөргән гайбәтче хатынга да тиңләп булыр иде. Нәтиҗәдә фараз кылырга яратучы кайберәүләр, шул негативны үзләренә баштанаяк сеңдереп, җиһанга апокалипсис юраугa ук алына. Чүп өстенә чүмәлә өелә.

Кешелекнең бүгенге төп проблемасы – техник, технологик прогресс тыелгысыз алга чапканда рухи алгарышның урында таптануы. Бүгенге рухи фәкыйрьлек, иман, әхлак, кешелеклелек сайлыгы. Хәтта диннәр дә йогынтысын җуеп бара. Халык артык «грамотный» булудан – күрмәгән, тотып карап булмаган нәрсәләргә ышанмаудан гына түгел. Аерым дини агымнар, дин байрагы астына сыенган террористик оешмалар, виллалар сатып алып яманаты чыккан дин башлыклары диннең дәрәҗәсен төшереп тора. Шул сәбәпле дә, ансыз да акча, мал артыннан чабуны кыйбла иткәннәр армиясе чүмәкәй тулышкан. Һәм бу хәлләрнең күбесе, ахыр чиктә, Путин Валдай форумында тәнкыйтьләгән капитализмга, аның «казаныш»ларына барып төртелә. Ул стройның матди яктан да, рухи яктан да мәгънәсез булуын Маркс белән Энгельс, Плеханов белән Ленинннан башлап бүгенге коммунистларга чаклы даими әйтеп килә. Аны – бәндәдәге затсыз сыйфатларны эшкә җигүче («Йөз процентлы табыш дигәндә капитал иң әшәке җинаятькә дә әзер». – К.Маркс, «Капитал») стройны тарих чүплегенә озатырга теләүчеләр элек тә булды, хәзер дә җитәрлек. Тик ничек итеп? Социализм барып чыкмады. Капитализмны нәрсә, нинди җәмгыять алыштырырга тиеш? Җавап юк.

Акрынлап үзе игә килер дип өметләнү – беркатлылык. Ә бит Октябрь инкыйлабыннан соң капитализмга кеше чырае керә башлаган иде. Көнбатыш дәүләтләрендә 8 сәгатьлек эш көне нәкъ менә шул вакыйгадан соң яралды. Курку, бездә дә шундый хәлләр килеп чыгар дигән шөлләү тудырды аны. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң социалистик лагерь яралу «швед социализмы» дигән феномен китереп чыгарды. Байларга – моңарчы күрелмәгән прогрессив салым, гади халыкка – тиңе булмаган социаль яклаулар. Тик бу тәҗрибә Төньяк Европадан бар дөньяга таралсын өчен яңа тетрәнүләргә юл ачып булмый. Ә ансыз да капитализм яхшырыр, иманга килер, байлар белән ярлылар арасындагы упкын сай чокырга әйләнер дию – капиталның асылын белмәү. «Форбс» исемлегендә торганнар Маркс әйләнешкә керткән өстәмә түләүдән (прибавочная стоимость) һичкайчан баш тартмаячак, яңа формациягә юл куймаячак. Глобаль капитализм – дөньяви узурпатор. Бүгенге дөньяның хуҗасы. Акча капчыклары өстендә аякларын салындырып утырганнарны аннан алып атар көч бүген юк, күренми. Дәүләт җитәкчеләренең дә күбесе үтә байлар йогынтысы астында. Ким дигәндә алар белән исәпләшергә мәҗбүр. Алар тагарагыннан туенганнары, халыкны өченче, бишенче планга куйганнары да юк түгел.

Халык, кешеләр дигәннән. Вазгыять үзгәрсен дигәндә алар нигә сәләтле? Әллә бернигә яраксызмы? Демократик институтлар эшләп торган, тормыш дәрәҗәсе югары булган илләрдәге халыкның глобаль капитализмга әллә ни дәгъвасы юк. Чөнки байның ярлы хисабына яшәве ул тарафларда бик сизелми, капитал тудырган бәлаләр дә күзгә азрак төртелә. Ә фәкыйрьлек яшәгән тарафларда халык караңгылыкта. Аны яктыга чыгардыңмы, бүлешәсе булачак. Сәнәктән көрәк булганнар бүлешергә яратмый. Саран булу өстенә, алар әле шәфкатьсез, әхлаксыз да. Гади кеше дә, караңгылык сәбәпле, активрак, иманлырак, гыйлемлерәк булырга атлыгып тормый. Пролетар язучысы Горький: «Кеше ул горур яңгырый», – дип язган булса да. Кеше, адәми зат дигәндә, «Колыма хикәяләре» авторы Варлам Шаламовның бәяләмәсе чынбарлыкка якынрак, миңа калса. «Адәм белән Кант арасы адәм белән ат арасыннан ераграк». («Интеллектуальное расстояние от простого человека до Канта, во много раз больше такого же расстояния от простого человека до его рабочей лошади».) Гади телгә күчергәндә, Шаламов гади кешедәге гыйбадлыкның һаман да югары калуын әйтә. Чыннан да дөньяны аңлау, танып белүдә бик күпләрнең буе җитмәслек биеклеккә ирешкән Иммануил Кант янында ашау һәм күңел ачу кайгысы белән генә яшәгән обыватель бөҗәккә тиң. Нәкъ шушы хәл кешелек бәлаләренең башында тормый микән?

Капитализмга альтернатива бармы дигәндә, без алда әйтелгән ике төп каршылыкка килеп төртеләбез. Капиталның аренадан китәргә теләмәвенә һәм гади халыкта капитализм китергән бәлаләрдән котылырлык егәр булмауга. Ленинны янә бер кат искә төшереп һәм үзгәртеп: «Низы не могут, верхи не хотят», – диясе генә кала.

# МАЯК КЕБЕК ЮЛ КҮРСӘТӘ

**Мирас**

**140 ел элек нигез салынган мәчет тарихи урынына кайтты. Балык Бистәсендәге Олы Елга авылында төзекләндерү эшләреннән соң агач мәчет кабат ачылды. Чара Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашында узды.**

«Татар-информ» / Салават Камалетдинов

**Белешмә**

**Олы Елга авылындагы агач мәчет – XIX гасырдагы татар агач архитектурасы һәйкәле, татар агач сәнгате үрнәге. 1993 елда аны мәдәни мирас объекты дип таныйлар.**

Тарихка күз салсак, Олы Елга авылындагы мәчет 1879 елда төзелә. Җәмигъ мәчет 1937 елга кадәр эшли. Соңрак бина хуҗалык максатларында кулланыла. Хәзерге вакытта ул Татарстандагы иң борынгы агач мәчет санала. Төзекләндерү эшләре вакытында белгечләр мәчет диварының 70 процентын саклап кала алган. Моннан тыш ике терәк колонна белән манара нигезе торгызылган, гыйбадәт заллары эшләнгән, мәчетнең тышкы бизәлеше һәм декоратив өлешләре әзерләнгән. Төзекләндерү эшләре 2019 елның гыйнварында башланган иде. Моның өчен 50 млн сумнан артык акча тотылган.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов аны төзекләндерүдә катнашкан кешеләргә рәхмәтен белдерде.

– Мәчетне ата-бабаларыбыз 140 ел элек төзегән. Бик күп вакыт узуга карамастан, уртак көч белән без бинаны саклап кала алдык. Әлеге мәчет безнең халкыбыз һәм динебезгә бик күп файда китерәчәк, – диде ул.

Президент киләсе елда Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу федераль дәрәҗәдә билгеләп үтеләчәген искәртте.

– Бу уңайдан без Казанда Җәмигъ мәчетне төзергә ниятлибез. Ә инде бүген сезнең белән бергә республикада иң борынгы агач мәчетне ачабыз. Мин сезне әлеге әһәмиятле вакыйга белән котлавыма шатмын, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Тарихи бинаны ачу тантанасында Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин да бар иде. «Мөселманнар өч бәйрәмне билгеләп үтә бүген. Бу – Мәүлид – Мөхәммәд (с.г.в) пәйгамбәрнең туган ае, җомга һәм борынгы мәчет ачылу көне. Бу – соңгы елларда Татарстанда төзекләндерелгән өченче борынгы мәчет. Моңа кадәр Әтнә районындагы Түбән Бәрәскә авылында һәм Казандагы Әҗем мәчетен ачкан идек», – диде мөфти.

Чарада катнашучылар тантанадан соң җомга намазын яңа мәчеттә укыды. «Мәчет кешеләр тормышында зур роль уйный. Авылга кергәндә ул ерактан ук күренә, маяк кебек юл күрсәтә һәм бәла-казадан саклый. Бу мәчет – безнең байлыгыбыз», – диде төзекләндерелгән мәчетнең имам-хатыйбы Таһир хәзрәт Гайнетдинов.

Татарстанның Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин белдергәнчә, мәчетне төзекләндерү теләген авыл халкы үзе җиткергән.

– Мәчет бинасы хуҗалык ихтыяҗлары өчен кулланылган, ул авария хәленә җиткән һәм бу бинага бик җитди төзекләндерү таләп ителә иде, – диде комитет рәисе.

Шунысын да искәртеп үтик: мәчет башта Вологда өлкәсендә, аннан соң Казанда төзекләндерелгән.

## ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

**Босния һәм Герцеговина тарафына очучы «Ансат»лар саны ишәергә мөмкин. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның сәүдә һәм икътисади хезмәттәшлек буенча Россия – Босния һәм Герцеговина Хөкүмәтара комиссиясе рәистәше, Босния һәм Герцеговинаның тышкы сәүдә һәм икътисади мөнәсәбәтләр министры Сташа Кошарац белән очрашуында шундый фикер әйтелде.**

Очрашу Казан Кремлендә узды. Исегезгә төшерәбез: Казанда сәүдә һәм икътисади хезмәттәшек буенча Россия – Босния һәм Герцеговина Хөкүмәтара комиссиясенең чираттагы утырышы узды.

Президент билгеләп үткәнчә, Татарстан – Россиядә икътисади яктан иң нык үскән төбәкләрнең берсе. Нефть-газ-химия комплексы, машина төзелеше өлкәсе һәм башка юнәлешләр нык үсештә. Моннан тыш республика авыл хуҗалыгы буенча да алдынгылар исәбендә бара. «Хезмәттәшлек өчен мөмкинлекләр җитәрлек, аеруча – икътисад өлкәсендә. Без алардан тулы күләмендә файдаланырга тиеш. Үзара хезмәттәшлек тәҗрибәбез бар. Аерым алганда, өч «Ансат» вертолетын җибәрдек. Алга таба барырга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов. Президент шулай ук Татарстаннан шиннар, полимер, каучук һәм «КамАЗ» автомобиль продукциясен җибәрү мәсьәләләрен карарга тәкъдим итте. Сташа Кошарац, үз чиратында, сәүдә элемтәләрен үстерүнең ике яклы хезмәттәшлекне ныгытуда төп шарт булып торуын әйтте. «Вертолетлар сатып алу өлкәсендә хезмәттәшлек тәҗрибәсенә ия булуыбыз бик әйбәт. Без аларны әле тагын сатып алырга телибез», – диде министр.

***

**Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Шәүкәт Мирзиёевны Үзбәкстан Президентын сайлауда җиңүе белән тәбрик итеп, котлау юллады. 24 октябрьдә узган сайлауда Мирзиёев өчен халыкның 80,12 проценты тавыш биргән.**

«Үзбәкстан Республикасы Президентын сайлауда ышанычлы җиңүегез уңаеннан иң җылы котлауларны кабул итегез. Сезнең сайлануыгыз – Үзбәкстан гражданнарының көчле, тәҗрибәле дәүләт башлыгы буларак сезгә ышанычы югары дәрәҗәдә булуының бәхәссез дәлиле», – дигән Рөстәм Миңнеханов. Һәм ике арадагы мөнәсәбәтләрнең тагын да ныгыячагына өмет белдергән.

***

**Республика Президенты «Биосфера-Фиш» балыкчылык комплексының өченче өлешендә булды. Рөстәм Миңнехановка биредә комплексның эш йомгаклары турында сөйләделәр. Хәзерге вакытта технологик җиһазларны урнаштыру эше алып барыла. Биредә Дания технологияләре буенча һәркайсы 1,8–2шәр килолы 100 тонна форель һәм 2 миллион данә маймыч үрчетү планлаштырыла.**

Моннан тыш биредә «Эко-Парк Биосфера» туристлык-ял зонасын үстерү күздә тотыла. Моның өчен ресепшн, ресторан, кечкенә йортлар төзү эшләре башланган да инде. Ял зонасын булдыруга 2,5 миллиард сум күләмендә инвестиция җәлеп итү күздә тотыла. Барлыгы 250 эш урыны булдырылачак.

Балыкчылык комплексы җитәкчелеге Президентка җирләрне рәсмиләштерү мәсьәләсендә ярдәм итү үтенече белән мөрәҗәгать итте. Шулай ук комплексны алга таба үстерү өчен сыйфатлы электр энергиясе, тиешле күләмдә газ белән тәэмин итүнең кирәклеге әйтелде. Рөстәм Миңнеханов профильле министрлыклар һәм оешмаларга «Биосфера-Фиш»ка бу мәсьәләләрдә ярдәм итәргә һәм эшне тизләтергә кушты.

## МИНТИМЕР ШӘЙМИЕВ:

# «АКЫЛ БЕЛӘН ЭШ ИТИК! БЕРДӘМ БУЛЫЙК!»

**Татарстанның беренче Президенты, Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев җанисәп уңаеннан халыкка мөрәҗәгать итте.**

«Татар-информ»

«Кадерле милләттәшләр! Бөтенроссия халык исәбен алу – илнең бөтен халкы катнаша торган, ил үсеше өчен кирәкле, даими үткәрелүче чара. Аңа катнашу – ирекле гамәл, һәркемнең үз ихтыярында. Телне, милләтне саклау күзлегеннән карасак, җанисәп – безнең ни дәрәҗәдә татар булуыбызның иң ачык күрсәткече.

Һәрберебез үз нәселенең, үз гаиләсенең үткәненә күз салсын. Ата-бабалары ничек яшәгән? Аларга үз милләтен, телен саклап исән калу бервакытта да җиңел булмаган. Моны тарихтан да беләбез. Кайберәүләр, хәтта ватанын, ана телен яки татарча исемен югалтса да, милли җанын югалтмаган.

Чөнки милли хис – телисеңме, теләмисеңме – ана сөте белән кереп, каныбызда яши. Ата-бабаларыбызның васыяте, әманәте булып яши. Бу әманәтне тиешле иясенә – балаларыбызга, оныкларыбызга, яшь буынга, гомумән – киләчәгебезгә тапшырырга тиешбез! Әманәткә хыянәт итмик, милләттәшләр!

Безгә тапшырылган иң изге әманәт – ана телебез, милләтебез бездә тукталып-югалып калмаска тиеш. Аны буыннан-буынга җиткерү — һәрберебезнең милләт каршындагы иң җаваплы бурычы. Әти-әниләребезне ярату, ата-бабаларыбызны ихтирам итү билгесе. Моны, халык исәбендә катнашып, турыдан-туры белдерү – иң үтемле, иң нәтиҗәле чара.

Без бу хокуклардан, әти-әни, әби-бабайларыбыз теләгәнчә, горурланып, тулысынча файдаланырга тиешбез. Акыл белән эш итик! Бердәм булыйк! Бердәм булсак, без, һичшиксез, булдырырбыз!» – диелә мөрәҗәгатьтә.

# СЫНАЛУ ЕЛЫ ДӘВАМ ИТӘ

**Авыл хуҗалыгы**

**Татарстанда 461,3 мең гектар мәйданда көзге культуралар чәчелгән. Белгечләр әйтүенчә, шуларның 16,5 мең гектар мәйдандагысы кышны начар хәлдә каршы алачак.**

vk.com

Быелгы җәйнең артык эссе һәм коры килүе авыл хуҗалыгы тармагында эшләүчеләрнең кәефен кырды. Алар җәй буе төшмәгән яңгырны көзен булса да күрергә өметләнгән иде, тик сентябрь, октябрь айлары да авыл хуҗалыгы өчен ул яктан уңышлы булмады.

– Кәефләр шәптән түгел: җир кышка коры китә, – ди Кукмара районының баш агрономы Илдар Габбасов. – Яңгырлар булмау сәбәпле, уҗымнар башта тишелеп чыга алмады. Аннан соң ныгып китәргә өлгермәделәр. Туфрак шулкадәр коры ки, керткән ашлама да эри алмыйча ята. Яңгыр булса, эреп туфракка сеңәр иде дә, ашлыкларга файдасы булыр иде. Менә шул процесс булмады быел. Җәе генә түгел, көзе дә безгә каршы эшли. Сыналу елы дәвам итә.

Илдар Габбасов әйтүенчә, быел районда көзге культуралар 6800 гектар мәйданда чәчелгән.

– Башка еллар белән чагыштырганда, азрак. Чөнки дым булмагач, зурга өметләнеп булмый. Монысын да шикләнеп кенә чәчтек. Башта яңгыр көттек, аннан соң гына чәчүгә кереп киттек. Сарман, Саба, Арча районнарындагы хезмәттәшләр белән аралашып торабыз. Аларда да шул ук хәлләр. Күршеләребез балтачлыларга бу уңайдан бәхет елмайды, – диде агроном.

Кешеләр генә түгел, уҗымнар да кышка әзерләнә башлады инде. Яңгыр яуса, файдасы гына булачак.

– Туфрак коп-коры. Беркөн бераз яңгыр явып узды, тик ул гына хәлне берничек тә коткара алмый. Дым туфракка шул ук минутта сеңеп бетте. Безгә хәзер ким дигәндә 40–50 мм тирәнлектә дым кирәк, – диде ул.

«Россельхознадзор»ның Татарстан буенча идарәсе белгечләренең дә фаразлары сөендерерлек түгел. Аларның сүзләренә караганда, октябрьнең икенче декадасы гадәти нормадан 3–5 градуска җылырак булды. Һәм 19–20 октябрьдә, ягъни башка еллар белән чагыштырганда, 8–13 көнгә соңрак калып суытты.

– Болытлы һава торышы һәм температура соңрак чәчелгән уҗымнарга кышка әзерләнер өчен яхшы шартлар тудырмады, – ди «Россельхознадзор» филиалы җитәкчесе урынбасары Любовь Занина.

Гәрчә Илдар Габбасов фикеренчә, кинәт суытып җибәрүнең зыяны юк. Анысы уҗымнарны чыныктыра гына. Иң начары – туфракта дым булмау.

Агрономның бу фикерен Любовь Занина да куәтләде. Белгеч сүзләре буенча, быел республикада уҗымнар 481,1 мең гектар мәйданны алып тора. Шуларның 272,2 меңе – яхшы хәлдә, 151,5 меңе – канәгатьләнерлек, 16,5 мең гектар җирдәге көзге культуралар кышка начар хәлдә керә. Моннан тыш, көзге арыш – 7,2 мең, көзге бодай 33,6 мең гектар мәйданда тармакланмаган.

– Чәчүлекләрнең начар хәлдә булуының сәбәпләре – туфракның коры булуы, соң һәм тирән утыртылуы, – дип аңлата Любовь Занина.

«Россельхознадзор» идарәсе белгечләре әйтүенчә, быел 105,9 мең тонна орлык чәчелгән. Иң зур мәйданны көзге бодай алып тора. Арыш исә көзге чәчүлек мәйданнарының 22,9 процентын тәшкил итә.

Болардан кала, белгечләр авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә кимерүчеләргә каршы көрәш алып барырга киңәш итә. Чөнки тикшерелгән мәйданнарның 43,8 процентында (ягъни 69 мең гектар мәйданда) тычкан оялары табылган.

Зөһрә САДЫЙКОВА

# ӘФГАН ТАТАРЛАРЫ ЯРДӘМ КӨТӘ


pixabay.com

**Милләттәшләр**

**Әфганстанда яшәүче татарлар өчен шәп яңалык бар: Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов авыр хәлгә юлыккан милләттәшләребезгә ярдәм кулы сузарга карар кылды. «Әфганстанда яшәүче татарларның авыр хәле турында Президентка җиткерелде. Бу җәһәттән Татарстан вице-премьеры, «Милли шура» советы рәисе Васил Шәйхразыевка андагы татарларның санын һәм нинди ярдәм кирәклеген ачыкларга кушылды», – диде Президентның матбугат сәркатибе Лилия Галимова.**

### Он, шикәр, үсемлек мае кирәк

Аңа кадәр Мөселманнарның ватанпәрвәрлек хәйрия фонды генераль директоры Рөстәм Хәбибуллин, «Татар-информ» агентлыгында журналистлар белән очрашып, Әфганстанда яшәүче милләттәшләребезнең тормышы, хәл-әхвәлләре белән таныштырган иде. «Әфганстанда хәрби бәрелешләр бара. Өстәвенә АКШ банк счетларын япты. Шуңа күрә берничек тә акча белән эш итеп булмый. Гаиләләр ачлыктан интегә. Балалар үлә. Беренче чиратта он, шикәр, үсемлек мае белән тәэмин итә алсак, әйбәт булыр иде, – дип үтенечен җиткерде ул. – Гуманитар ярдәм төялгән машиналар өч көндә барып җитә ала. Аны без, Үзбәкстан аша кертеп, милләттәшләребезнең үз кулларына тапшырыр идек. Тарату буенча бернинди проблема да булмас дип уйлыйм. Тик моны бер ай эчендә хәл итәргә кирәк, чөнки кыш җиткәч, юлларга кереп булмый. Анда яшәүчеләр безгә үлгән балаларының фотоларын җибәрәләр, Әфганстан татарлары лидерларыннан ярдәм сорап хатлар килә. Өч ай элек без аларга дарулар җибәрә алган идек. Хәзер инде бөтен өметебез – Татарстанда».

Очрашуга килүчеләр сөйләвенчә, Әфганстанда татарлар башлыча Көнчыгыш Азия илләре чигендә, төньякта урнашкан провинцияләрдә яши. Анда талиблар килеп җитмәгән әле, ди алар. Җирле халык үз авылларын, өязләрен күз карасыдай саклый. Әмма халык саны кискен төстә кими. Сугыш булгач, өйләреннән чыгып китәләр дә эзсез югалалар икән.

Әле күптән түгел генә Әфганстанда яшәүче татарларның бернинди статусы булмаган. Аларны хөкүмәт милләт буларак танымаган. Татарларга хәтта зиратта мәет күмәргә дә ярамаган. Татарлар анда яшәүче үзбәкләргә, таҗикларга, төрекмәннәргә елышкан. Шуңа күрә дә алар башка милләт халкы булып язылырга мәҗбүр булганнар. Әфганстан Конституциясенә кертелеп, татар милләте дигән статус белән электрон паспортлар бирелү эше җайга салынгач кына хөкүмәт алышыну барысын да челпәрәмә китергән.

Татарлар арасында гыйлемле кешеләр, медицина хезмәткәрләре, хөкүмәттә хезмәт итүчеләр дә булган. Кышлакларда яшәүчеләр авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнгән. Үстергән җиләк-җимешләрен үз арасындагы эшмәкәрләр башка илләргә, бигрәк тә Һиндстанга, Иранга, Пакьстанга сата алганнар. Тик сугыш башлангач, хәлле кешеләрнең күбесе күченеп киткән. Ярлыраклары, китәргә мөмкинлек булмаганнары торган җирендә яшәп калган. «Шуңа күрә дә аларның тормышы фаҗигале төс ала бара. Үстергән җиләк-җимешләрен, җитештергән продукцияләрен дә сата алмыйлар. Акча булмагач, террор күренешләре дә арта», – ди Рөстәм Хәбибуллин.

### Татарлар кайдан килгән?

Тарих битләренә күз салсак, Әфганстан территориясендә татарлар мең елдан артык, Хәрәзм чорыннан бирле яшиләр икән. Аларның күбесе Урта Азиядән күченгән. Заманында «Ефәк юлы» буйлап утрак тормыш алып барганнар, әлбәттә инде, сату-алу белән шөгыльләнгәннәр. Хәзер исә бу илдә миллионнан артык татар яши дип исәпләнә. Электрон паспортны 50 мең татар рәсмиләштерергә өлгергән. Башка саннар да бар. Әмма көчле ассимиляция барганлыктан, төгәл исәп-хисап ясалмаган. Ни кызганыч, тел дә югалган. Алар бүген фарсы, үзбәк, пушту телләрендә сөйләшәләр. Төрле җирләрдә яшәгәнлектән, аралашу мөмкинлеге дә чамалы. Әмма бүген Әфганстан татарлары берләшергә омтыла. Алар рәсми төстә татар дип теркәлү яклы. Рөстәм Хәбибуллин әйтүенчә, Россия үзәгендә татарлар яшәвен күбесе белмәгән. Татарстан дигән җөмһүрият барлыгын ишеткәч, бик шатланганнар, күңелләре күтәрелеп киткән. Очрашуда әйтелгәнчә, Әфганстанда ике татар мәктәбе дә ачканнар. Тик дәреслекләр булмау гына авырлыклар тудыра икән. Шулай да күңелләрен төшермиләр. Татарстан Президентына да, Бөтендөнья татар конгрессына да мөрәҗәгать белән чыкканнар.

Рөстәм Хәбибуллин шулай ук Татарстанда Әфганстан илчелеге ачу идеясен дә җиткерде. Лилия Галимова бу эш белән Россия Тышкы эшләр министрлыгы шөгыльләнгәнен әйтте.

Моннан шактый еллар элек мин үзәк каналларның берсендә Әфганстанда яшәүче татарлар турындагы очраклы гына бер тапшыруга юлыккан идем. Шунда татар авылларын күреп бик гаҗәпләндем. Учак янында күмәч пешерүче хатыннар алып баручының сорауларына нииндидер телдә җавап бирделәр дә (ул бәлки фарсы теле булгандыр) аннан соң саф татар телендә, өздереп, «Туган тел»не җырлап җибәрделәр. Тәрҗемәче: «Үзебез сөйләшә алмасак та, җырларыбызны әби-бабайларыбыз туган телебездә өйрәтеп калдырды», – дип моңлануларын җиткерде. Шунысы бигрәк тә йөрәккә уелып калган.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

# КОТЛЫЙБЫЗ!

«Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе житәкчесе **Дёгтева** Ольга Павловнага, EuroSkills Graz 2021 һөнәри осталык буенча Европа чемпионатында катнашучыларның югары күрсәткечләргә ирешүенә өлеш керткәннәре өчен «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциячел булмаган оешмасының халыкара эксперты **Белякова** Елизавета Владимировнага; «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциячел булмаган оешмасының халыкара эксперты **Зимина** Юлия Анатольевнага; «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциячел булмаган оешмасының халыкара эксперты **Ильиных** Мария Михайловнага; илкүләм җыелма командасы техник директорының урынбасары, «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциячел булмаган оешмасының халыкара эксперты **Крюков** Андрей Игоревичка; «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциячел булмаган оешмасының халыкара эксперты **Парамонов** Александр Ивановичка; «Дизайн һәм Сервис халыкара институты» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесенең беренче проректоры **Усынин** Максим Валерьевичка; «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студенты **Дюбанов** Владислав Дмитриевичка; «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең IT-cube ИТ-иҗат балалар үзәге технигы, «А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе студенты **Ипатов** Александр Игоревичка; «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесе студенты **Камратова** Евгения Александровнага; «В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты (Икътисад, идарә һәм хокук институты)» югары белем бирү хосусый мәгариф учреждениесен тәмамлаучы **Рөстәмова** Сагдиана Ришат кызына; «Казан медицина көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем белем бирү учреждениесе студенты **Садыйкова** Екатерина Александровнага; Россия Федерациясе Кулланучылар җәмгыятьләре үзәк берлегенең «Россия кооперация университеты» югары белем бирү автоном коммерциячел булмаган мәгариф оешмасының Казан кооперация институты (филиалы) производствода эшкә өйрәтү мастеры **Салатова** Вероника Николаевнага; «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе студенты **Сейдаметов** Эльдар Эльвир улына; «Казан сәүдә-икътисад техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесенең «Ворлдскиллс» хәрәкәтен үстерү буенча менеджеры **Туривной** Степан Сергеевичка Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәте белдерелде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары – Казан шәһәрендәге департаменты директоры **Мөхәммәтшин** Дамир Фәрит улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Күпьеллык намуслы хезмәте, мәгариф системасын үстерүдәге казанышлары һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләүгә зур өлеш кертүе өчен «Халыкара компетенцияләр үзәге – Казан мәгълүмат технологияләре һәм элемтә техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директорының фәнни-җитештерү һәм инновация эшчәнлеге буенча урынбасары – уку-укыту үзәге җитәкчесе **Рамазанова** Дамира Әкъмәл кызы Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Орлова** Вера Викторовна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың төзелеш тармагын үстерүгә өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Әлмәт инженерлык-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте маляры **Камалетдинова** Фәнүзә Мәсәлим кызына, «Стройсервис» акционерлык җәмгыятенең экскаватор машинисты **Мөһәммәдиев** Илсур Мөлек улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Түбән Кама шәһәренең «Шәһәр электр транспорты» муниципаль унитар предприятиесе трамвай йөртүчесе **Петрова** Татьяна Анатольевнага, Түбән Кама шәһәренең «Шәһәр электр транспорты» муниципаль унитар предприятиесе юллар монтажчысы **Проценко** Сергей Алексеевичка, «Пассажирлар йөртүне оештыручы» муниципаль казна учреждениесенең диспетчерлык системаларына технологик хезмәт күрсәтү бүлеге өлкән диспетчеры **Сургучева** Татьяна Николаевнага, Түбән Кама шәһәренең «Шәһәр электр транспорты» муниципаль унитар предприятиесе күчмә составны төзекләндерү буенча слесаре **Чурашов** Алексей Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Транспорт тәэминаты өлкәсендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге кунакларны йөртү машиналары колоннасы автомобиль йөртүчесе **Гыйлаҗев** Наил Ниязбәк улы; рус халкының рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен саклауга һәм үстерүгә зур өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Казан шәһәренең «С.Сәетгалиев исемендәге мәдәният сарае» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең «Русская песня» халык хоры җитәкчесе, «Казанның Рус милли-мәдәни берләшмәсе» җирле иҗтимагый оешмасы Советы әгъзасы **Измайлова** Светлана Владимировна; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы эчке хезмәт полковнигы **Чернов** Геннадий Александрович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән** бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчесе **Гыйсмиев** Нияз Рәхимҗан улы, Татарстан Республикасы гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы **Захаров** Сергей Дмитриевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең эксплуатация бүлеге автомобиль йөртүчеләре **Закирҗанов** Рәшит Әдһәм улына, **Мөхетдинов** Айрат Хафиз улына, **Хәкимов** Рәдиф Нәгыйм улына, «БИГЕШ АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыятенең транспорт һәм авиация куркынычсызлыгы хезмәте смена башлыгы **Жевлаков** Роман Анатольевичка, «БИГЕШ АЭРОПОРТЫ» акционерлык җәмгыятенең махсус транспорт хезмәте һәм аэродром комплексы старт колоннасы автомобиль йөртүчесе **Шамаров** Әхнәф Мөбәрәкҗан улына, «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең тимер юл транспорты идарәсе башлыгы **Ибраһимов** Айрат Рәүф улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

# АВЫЛ: АРТУГАМЫ, КИМҮГӘМЕ?

**Фикер**

**Росстат октябрь башында 2021 елда авыл хуҗалыгында җитештерүнең кимүгә таба баруын хәбәр итте. Икътисадның гомуми үсеше 5 проценттан артып барганда, авыл хуҗалыгында җитештерү акчалата исәпләгәндә 3,4 процентка кимегән икән.**

Бу уңайдан Мәскәү журналистлары менә болайрак яза: «Авыл хуҗалыгы продукциясенең бәяләре узган елның гыйнвар – августы белән чагыштырганда 20 процентка диярлек артты. Үсемлек маена бәяләр рекордлы – 27,1, шикәргә 146,8 процентка күтәрелде. Парадокс: бәяләрнең шулай артуына карамастан, агросекторның гомуми җитештерүе акчалата исәпләгәндә кими». Авылдан ерак журналистлар, бәлки, белеп тә бетерми торганнардыр: шикәр заводлары һәм май сыгу предприятиеләре шәһәрләрдә урнашкан һәм аларны авыл хуҗалыгы тармагына кертсәң дә шартлы рәвештә генә кертеп була. Кошчылык фабрикалары белән дә эш шулайрак тора. Болар нигездә сәнәгать предприятиеләре һәм аларны авыл белән бары тик чимал гына бәйли. Һәм соңгы продукциянең бәясе күтәрелү авылга файда бирми диярлек. Аннан соң шикәр чөгендере игү, көнбагыш үстерү белән авыл хуҗалыгының бик кечкенә өлеше генә шөгыльләнә. Шуңа күрә шикәр белән көнбагыш маена бәяне тагын берничә тапкыр арттырсаң да, алар авыл хуҗалыгы продукциясенең тулаем акчалата күләменә бик әллә ни өстәмиләр. Ә менә вакытында яуган бер яңгыр нәтиҗәсендә миллиардлаган һәм дистә миллиардлаган сумнар өстәлә яисә тартып алына… Табигать шартларына бәйле булдыңмы, җитештерү синең тырышлыгыңнан гына тормый. Әнә Европада җилләр акрын исә башлау энергия чыганакларына бәяләрне күтәрүгә никадәр өлеш кертте. Җил станцияләре электр эшләүне туктатты чөнки.

Ә ашлык һәм печән муллыгына җил дә, яңгырлар да, кояш та үз өлешен бик мул кертә. Кояшлы көннәр аз булса, ашлыкның тулай күләме дә, сыйфаты та түбәнәя. Үзе белән бозлы яңгыр ияртеп килгән бер көчле җил меңнәрчә гектарны уңышсыз калдыра һәм миллионлаган сумнарны җилгәрә ала. Быел күрдек бит инде: яңгырны күктән тартып алырдай булдык – яумады. Бәс, шулай булгач авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүнең физик күләме кими, ул кимегәч, бәяләр артса да, акчалата керемнәр үсә алмый. Әйтик, ашлыкка бәя күтәрелү ул барыннан да бигрәк авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә китереп суга: сөт һәм ит җитештерүне файдасызга әйләндерә. Интернетта фермерлык белән шөгыльләнүче Россия блогерлары хор белән кычкыралар әнә: сыерларны бетерәбез, диләр. Бүтән керемебез юк иде, шушы сыерларга гына карап тора идек, суймыйча булмый инде, дип зар елыйлар.

Газета хәбәрчесе авылда яшәүче буларак үзе дә күреп тора: байтак хуҗалык фураж бәяләре күтәрелүгә сугым пычагы белән протест белдерде. Мөгезле эре терлекнең баш саны кимү – шәхси хуҗалыкта гына түгел, эре инвестор хуҗалыкларына да хас күренеш. Һәм бу быелгы гына түгел, күпьеллык тенденция. Татарстан статистикасына гына күз төшереп карыйк. 2017 елда мөгезле эре терлекләрнең саны алдагы елның 99,4 проценты кадәр генә булган. 2018дә тагын да кимеп, 97,7 процентка гына калган. 2019 күрсәткече дә алдагы елның 98,4 проценты кадәр генә. 2020 елда да терлекләрнең баш саны алдагы елның 97,8 процентын гына тәшкил итә. Игътибар итегез: яңгырлар вакытында явып, терлек азыгы мул булган елларны карадык әлегә кадәр. Сентябрь ахыры мәгълүматларын алдым. Ел башы белән ахырында саннар үзгәрә гадәттә. Быел кимү темплары куәтлерәк. Республика буенча мөгезле эре терлекнең баш саны алдагы елның 95,7 проценты кадәр генә. 2017 елның сентябрендә республика буенча йөз гектарга 18 баш мөгезле эре терлек туры килсә, быел бу сан 17 генә. Гектарның потенциаль мөмкинлекләре исә зур. Әтнә районында, мәсәлән, быел йөз гектарга 55 баш мөгезле эре терлек туры килә. Кама Тамагы районы быел терлекләрне күпләп бугазлаган: үткән елгының 29 проценты кадәр генә калдырган. Гаепләп язмыйм бу юлларны,

«ВТ» архивыннан

чөнки һава торышы районнарда ничек булуын белмим. Терлек азыгына кытлык булса, баш санын арттырудан мәгънә юк.

Менә бу югарыда язылганнар тәнкыйть сүзләре түгел. Икътисадта ике төрле үсеш бар. Экстенсив үсеш һәм интенсив үсеш. Беренчесен авыл хуҗалыгы мисалында карасак, терлекчелек продукциясен терлекләрнең баш санын ишәйтү юлы белән арттырасың. Бу оптималь юл түгел, әлбәттә. Җитештергәннең үзкыйммәте зур була, рентабельлек кечкенә. Интенсив үсеш исә продукцияне баш санын арттырмыйча гына күбәйтүне күз алдында тота. Бу очракта рентабельлек арта. Бер сыердан алынган сөт күләме зуррак була, ит тә шулай ук. Татарстан авыл хуҗалыгы нигездә икенче юл белән үсә. Сөт мисалында карыйк. 27 октябрьдә көнлек савым 3752,9 тонна тәшкил иткән. Бу узган елның шул көне белән чагыштырганда күбрәк. 2020 елның 27 октябрендә сан 3627,4 тонна булган. Быел бер сыердан уртача 16,9 литр сөт савылса, үткән ел 16,4 литр гына булган. Терлекләрнең баш саны кимү шартларында да күбрәк продукция алып була, димәк.

Саннар белән чуарламас өчен әйтеп кенә китик: терлекләрнең баш саны кимүгә карамастан, ит җитештерү күләме дә арта Татарстанда. Санны киметкән районнар да күп, билгеле, әмма тулаем республика буенча җитештерү берничә район тырышлыгы белән үсештә. Республика буенча беренче өч кварталда акчалата керем дә арткан. Үткән елгының 105 проценты кадәр. Димәк, Россия статистикасы – бер нәрсә, Татарстанныкы – икенче. Россиядә кимү булса, бездә арту. Әмма дә ләкин максат бит күләмне арттыру гына түгел, җитештерүне табышлы итү булырга тиеш. Ягулык-майлау материалларына, төзелеш кирәк-ярагына, техникага бәяләр котырып үскәндә, күбрәк җитештереп, акчалата керемең күбрәк булса да, табышка эшләү бик кыен. Җитмәсә, банк процентлары да арту ягына китте. Икътисадта баланс булмау, бәяләр гаделсезлеге гел авыл хуҗалыгына китереп суга бездә. Аз гына шартлар уңайсызландымы, нефтьчеләр үзләренә өстенлек һәм субсидияләр сорап шыр кычкыра башлый. Металлурглар шулай итә. Төзелеш компанияләре хөкүмәттәге үз лоббиларын эшкә җигәләр. Һәм алар файдасына карарлар кабул ителә гел. Ә менә авыл хуҗалыгын яклардай кешеләр күренми югарыда. Быел авыл икеләтә кыенлыклар алдында калды. Табигать шартлары белән кырыс сыналды, сәнәгать продукциясенә бәяләр үсү белән кысылды. Менә шул шартларда да үсә һәм җитештерә әле ул.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

**Белдерү**

**ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ**

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:296, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Чукай». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

**ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ**

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельных участков, выделяемых в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:422, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Уныш». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

**ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ**

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:562, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, паевый фонд СХК «Укмас». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

# ТОРМЫШ КӨЗГЕСЕ

## «ЯҢА ГАСЫР» КАНАЛЫНДА БАРЫБЫЗГА ДА КАГЫЛГАН ЯҢА СЕРИАЛ КҮРСӘТӘ БАШЛАДЫЛАР

Премьера

**Гаиләдә бер-бер хәл чыкмый тормый инде ул. Элек ул хәлләр башкачарак булса, хәзер ут сүнеп, интернетсыз калгач та өйдә тавыш чыга. Кыйммәтләр үзгәрә. «Бер-бер хәл» дә әнә шул турыда сөйли.**

realnoevremya.ru

«Яңа Гасыр» телеканалы бер-бер артлы ике яңа сериал тәкъдим итте. Президент каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм «Татнефть» компаниясе ярдәмендә «ТНВ» заказы буенча «Ватан – XXI гасыр» кинокомпаниясе төшергән «Бер-бер хәл» сериалы 26шар минутлык 40 сериядән тора. Премьера турында матбугат очрашуында сөйләштеләр.

Төп рольләрне Фирая Әкбәрова, Гамил Әсхәдулла, Радик Бариев, Зөлфия Вәлиева, яшьләрдән Эльвина Насыйбуллина һәм Азамат Зәйнуллин башкара. Баш режиссер – Алмаз Әкбәров. Сценарийны да Альберт Шакиров белән берлектә ул язган.

Леонард Дәүләтшин җитәкләгән кинокомпания төшергән әлеге сериал хакында бер сөйләгән идек инде. Төп максаты – тамашачыны милли һәм мәдәни традицияләр аша татар телен өйрәнүгә этәрү. Ике төрле милләт вәкиле кабызган гаилә учагын, андагы мөнәсәбәтләрне күтәргән сериалны төшергән команда. Ни өчен команда, чөнки журналистлар белән очрашу вакытында әлеге кинопродуктның режиссеры Алмаз Әкбәров, сериалда ни буласын сценарист белән генә түгел, төшерү мәйданчыгына җыелган бөтен кеше һәм шәхсән Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиев белән киңәшеп эш иттек, дип белдерде. «Монда Радик гаиләсе дә, Алмаз гаиләсе дә, Гамил абый гаиләсе дә бар», – дип өстәде сценаристларның берсе Альберт Шакиров. Шуңа микән соң инде: планлаштырган 30 серия урынына биш ай эчендә кырыкны төшергәннәр.

### «Мин бит монда берәүгә дә кирәк түгел...»

«Бер-бер хәл»нең тәүге серияләрен генә бәяли алсак та, аның ни турында буласын, күңелнең нинди җепләрен тартасын инде чамаларга мөмкин. Төп рольләрнең берсен уйнаучы Татарстанның халык артисты Радик Бариев әйтмешли, чын сериал төшергәннәр. Тормыш. Ничек бар, шулай.

Татар егетенең урыс кызына өйләнүе һәм, гомумән, катнаш никахлар – безнең өчен чит тема түгел. Гаиләдә үзара урысча сөйләшү тагын да якынрак. Гадәттә, татарча сериаллардан соң гыйбрәттән бигрәк, гайбәткә урын күбрәк кала. Никтер бу юлы алай булмас төсле.

«Мин бит монда берәүгә дә кирәк түгел...» Мәрьям әбекәйнең (Фирая Әкбәрова) бу сүзләре аеруча йөрәккә тия. Олыларга ихтирам мәсьәләсе – шулай ук үзәктә. Без булган бар игътибарыбызны «лайк»лар, маникюр, массаж, компьютер уеннары, эшмәшәкатьләргә биреп бетерәбез түгелме?

### Татарчалы-урысчалы сериал

«Бер-бер хәл»не караганнар һәм карарга җыенучыларда бер сорау туарга мөмкин: ни өчен татарча, дип чыгарган сериалда да урысча сөйләшәләр? Әйткәнебезчә, вакыйгалар катнаш гаиләдә бара. Монда килен дә, балалар да урысча сөйләшә. Алар аңласын, дип, гаилә башлыгы һәм аның әнисе дә чит телгә күчәргә мәҗбүр була. Сериалның төшерү командасы моның шулай ук кырыс чынбарлыкка туры килүе турында әйтте. Хәер, катнаш гаиләләрдә генә түгел, татар гаиләләрендә дә «тел яшереп», үзара урысча сөйләшәләр бит. Сериалда чын тарих сөйләнү бер сәбәп булса, икенчедән, сериалны төшергән вакытта ук Алмаз Әкбәров аның ике телле тамашачыга да юнәлтелгән булуына ишарә ясаган иде. Шулай булып чыкты да.

«Бер-бер хәл»дә урысча сөйләшкәне өчен төп рольләрнең берсен башкаручы Татарстанның атказанган артисты Зөлфия Вәлиевага шелтә белдерүчеләр табылган инде:

– Миннән: «Ни өчен Анастасия урысча сөйләшә?» – дип сорыйлар. Тагын ничек сөйләшсен соң ул? Гомумән, әлеге рольне башкару бик җиңел бирелде миңа. Урыс мәктәбендә укыгангадыр инде, икенче телгә күчү авыр булмады, – диде ул.

Кыскасы, сериалдан гаеп эзләгәнче, оныклар белән нинди телдә сөйләшүебез яки сөйләшәчәгебез турында уйлансак, хәерлерәк булыр кебек.

### Кайчан һәм кайдан?

Төп сорауларга күчсәк тә буладыр. «Бер-бер хәл» сериалын «ТНВ-Татарстан» каналыннан – 9.00, 14.45 һәм 22.00 сәгатьләрдә, «ТНВ-Планета» каналыннан 8.00, 21.25 сәгатьләрдә карарга мөмкин. Моннан тыш, сериалны «ТНВ»ның «Ютуб»тагы каналында да карап була. Дөрес, әлегә өч сериясен генә. Калганнарын исә ТВ аша күрсәтеп бетергәннән соң гына урнаштырачаклар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА


Белми калмагыз!

## «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»ГА ЯЗЫЛУЧЫГА – МИНИ-ТРАКТОР

БҮЛӘКНЕ АЛУ ШАРТЛАРЫ

БЕЛЕШМӘЛӘР ӨЧЕН ТЕЛЕФОН: 8-917-927-00-40

1 2022 елның беренче яртыеллыгына «Ватаным Татарстан» газетасына язылырга.

2 «Ватаным Татарстан»ның «ВКонтакте» төркеменә язылырга һәм мини-трактор уйнату турындагы хәбәргә репост ясарга. Яки «ВТ»ның «Инстаграм» сәхифәсенә язылырга, соңгы актуальдәге бәйге турындагы постны скриншот ясап, «ВТ»ның аккаунтын билгеләп, үзеңә урнаштырырга.

3 Язылу квитанциясен һәм «Инстаграм» яки «ВКонтакте» аккаунтыгызның сылтамасын безгә җибәрергә: «Ватсап» (89179270040) яки почта аша (420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт, «ВТ» газетасы редакциясе), яки электрон адреска (info@vatantat.ru).

Җиңүче җирәбә юлы белән ачыкланачак. Квитанцияләр 2022 елның 16 гыйнварына кадәр кабул ителә, җирәбә 20 гыйнвар көнне уйнатылачак.

*Акцияне оештыручы: «Ватаным Татарстан» газетасы ДБУ, акцияне уздыру вакыты 2021 елның 1 ноябреннән 2022 елның 15 февраленә кадәр. Тулырак мәгълүмат vatantat.ru сайтында.*

АКЦИЯНЕҢ ИГАНӘЧЕСЕ – «УРАЛЕЦ» СӘҮДӘ ЙОРТЫ

УРАЛЕЦ ТОРГОВЫЙ ДОМ МЫ ПРОДАЁМ НАДЁЖНОСТЬ

✓ мини-тракторлар;
✓ барлык төр тракторлар өчен запас частьлар;
✓ җир эшкәртү, чәчү, җыйнау өчен асылмалы җиһазлар.

Казан ш., Мамадыш тракты, 35А; Чаллы ш., Казан проспекты, 252/1; Әлмәт ш., Советская урамы, 42А.

ТЕЛЕФОННАР: 8-927-465-12-94, 8-987-931-55-50

## ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ЫСУЛЛАРЫ

1 ПОЧТА БҮЛЕКЧӘЛӘРЕНДӘ

2 ОНЛАЙН: vatantat.ru сайтындагы сылтама аша газетага язылу бик уңайлы һәм тиз. Программа үзе адымлап алып бара.

Әлеге QR ярдәмендә телефон аша газетага язылырга һәм акча түләргә мөмкин.

*2022 елның беренче яртыеллыгы өчен 6 айга язылу бәяләре*

П2435 атнага бер, җомга килә – 465 сум

П2409 Сишәмбе, чәршәмбе, җомга, шимбә килә – 1000,92 сум

Реклама 16+

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65, 222-09-70. E-mail: vtreklama@mail.ru


# МУНЧАЛАСЫЗ БУЛМЫЙ МУНЧАДА

## АНЫ ҮЗ КУЛЫ БЕЛӘН ЯСАУЧЫЛАР ӘЛЕ ДӘ БАР

**Юкә мунчаласы бүген кем өчендер тансыкка әйләнсә, шул ук вакытта аннан беркайчан аерылмаучылар да бар. Авылларда мунчала чыгару гадәте бөтенләй бетмәгән әле. Арча районының Наратлык авылында чимал әзерләү технологияләрен өйрәнеп кайттык. Ә сез мунчаланы сагынасызмы?**

Зөлфия Хәлиуллина

### Мунчаланы гел сорап торалар

Наратлык авылы бик кечкенә. Элек урманчылыкта мунчала ясаучылар 15ләп булса, хәзер бу эшне нибары берничә кеше генә башкара. Ни өчен дигәндә, өлкәннәр лаеклы ялга киткән, ә яшьләр юк.

– Быелгы җәй-көзнең матур килүе мунчала ясау өчен бик уңышлы булды. Мунчала һаман да кирәк. Аны оныттылар дип әйтеп булмый. Кеше химиядән табигыйга күчә башлады. Монда 16 ел эшлим инде. Гел сорап торалар, тик чимал гына җитми, – ди Арча районының Тукай урманчылыгы урманчысы Фәнил Мәгъсүмов. – Ихтыяҗ булгач, бәясе дә арта. Базарда 50 сум тора. Элек 9–12 сумнан сатсак, соңгы елларда ике тапкыр кыйммәтләнде. Мунчаланы Казанда ярминкәләрдә сатабыз. Пумала да ясыйбыз. Аны күбрәк металлургия заводлары станоклар себерү өчен ала.

Фәнил Мәгъсүмов әйтүенчә, олыраклар мунчаны юкә мунчаласыннан башка күз алдына китермәсә дә, яшьләр кибетнекен өстенрәк күрә. Мәгъсүмовлар балаларын, юкә мунчала белән юыныгыз, кибетнекен тотмагыз, дип өйрәтә.

– Бездә кунакта булучылар, мунчала каян аласыз, дип сорыйлар. Казанның танылган ресторан җитәкчесе хәтта балачагын искә төшерергә дип килгән иде. Заманасында үзе дә мунчала ясаган икән. Шәһәргә мунчала алып китте. Хәзер республикада Саба, Кайбыч районнарында гына мунчала чыгаралар дип беләм, – ди урманчы.

Мунчала чыгару технологиясе үзгәрми, ди Фәнил Мәгъсүмов. Ул аның тәртибен элек урманчылыкта эшләүче белгечләрдән өйрәнгән.

Монда әчетү, пешерү дигән төшенчәләр бар. Белгеч әйтүенчә, май уртасында юкәнең кабыгын салдыра башлыйлар. Агач юанрак булган саен, мунчала күбрәк чыга. Агачларның кабыгын аерып, июнь башында күлгә салып, агач белән батыралар. Кайрыларны салдырган көнне үк батырырга кирәк. Киптерергә ярамый. Өч ай суда әчегәч, сентябрьдә кабыкларны чыгарып, мунчаласын кубаралар. 6 метр итеп кисеп, уртасыннан бәйләп, кечкенә кибәнгә өеп куялар. Берничә көн шулай пешеп тора. Аннан махсус урынга киптерергә эләләр. Кояшлы булганда, ике көн дә җитә. Чимал шулай әзер була.

### МУНЧАЛА ЯСАУ СЕРЛӘРЕ

✓ Чимал булып җитешсен өчен, күлдә дүрт ай тотасы. Өлгермәсә, мунчала аз чыгачак.

✓ Мунчала нык булсын өчен, күлдән чыгаргач, кечкенә кибәндә пешеп ятуы мөһим.

✓ Ләмдә ятып каралган урыннарын аерырга кирәк. Мунчала сары, ак төстә булса матур.

### Башкасы кирәкми...

Бүген элеккеге кебек һәр мунчада юкә мунчаласы эленеп тормаса да, аны яратып кулланучылар аз түгел.

– Мин кечкенәдән юкә мунчаласы белән генә юынам. Тәнгә иң рәхәте шул. Балалар аны кулланмый. Кибеттән берьюлы унарны сатып алам. Шул ел буена җитә. Элек 45–65 сум торса, хәзер бәясе – 75 сум. Кибетче әйтүенчә, мунчаланы сыер имчәген юар өчен дә алалар икән, – ди Балтач районының Чутай авылында яшәүче Мәүҗидә Вафина.

Тәтеш районының Зур Әтрәч авылыннан Илһамия Алиева юкә мунчаласы иң йомшагы дип саный.

– Башта өстенә кайнар су салып, кер сабыны белән йомшартып, бер кат пычрагын чыгарам. Чайкап, мич ташына куеп, пешереп алам. Юкә мунчаласы тәнгә бик файдалы, – ди Илһамия апа.

Алексеевск районының Түбән Тигәнәле авылында яшәүче Гөлнур Сабирова әйтүенчә, яшьләрнең генә түгел, өлкәннәрнең дә хәзер мунчалага әллә ни исе китми. Тик картлар бик онытып бетерми икән әле.

### Мунчада юк, сәхнәдә генә...

Мөслим туган як музее директоры Назилә Бәдертдинова, безнең якларда мунчала ясаучы осталар хәзер юк, ди.

– Килен булып төшкәндә, каенатам гел юкә мунчаласы ясый иде. Юкә агачын буага салып әзерләде. Аның үлгәненә ун ел инде. Күп кеше кибетнекен куллана. Югыйсә юкәсе дә, буасы да бар. Авылларда эшсез кешеләр күп. Бер шөгыль, эш булыр иде. Юкә мунчаласының нәрсә икәнен белми торган буын үсә, – ди Назилә Бәдертдинова.

Зәй районының Имәнлебаш авылы мәдәният мөдире Энҗе Әхмәтҗанова да шул ук сүзләрне кабатлый. Мунчала чыгару өмәсе хәзер сәхнәдә генә күрсәтелә икән. Ни өчен дигәндә, мунчала чыгаручылар да, ясаучылар да калмаган. Хәзер бары тик гореф-гадәт буларак кына саклыйлар.

Сәрия МИФТАХОВА


**Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы**

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.

Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

**Тираж – 7405 данә**
**Гомуми тираж – 17243 данә**

**Газетага сертификат бирелде** Заказ 359

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й. «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

**www.vatantat.ru**

**info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru**

**89179270040**

**Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)**
**П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)**
**П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)**
**П2435 (җомга саны)**

ТЕЛЕФОННАР

**222-09-70** – кабул итү бүлмәсе
**222-09-73, 222-09-67** – баш мөхәррир урынбасарлары
**222-09-68** – авыл хуҗалыгы
**222-09-67** – фән һәм мәгариф
**222-09-64** – әдәбият, сәясәт һәм дин
**222-09-66** – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
**222-09-67** – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
**222-09-65** – реклама бүлеге
**222-09-72** – бухгалтерия
**222-09-73** – компьютер үзәге
**221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә**

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

**R** тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
**N** тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт. График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+